РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
ЭНТУГАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯНТУГАН
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27.05.2024 № 82-2

Янтуган авыл җирлеге муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының кадрлар эшен алып бару буенча аерым функцияләрне Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турында килешүгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 4 өлешенә ярашлы рәвештә, Буа муниципаль районы Янтуган авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Буа муниципаль районы Янтуган авыл җирлеге Советының 2022 елның 25 мартындагы 1-44 номерлы «Буа муниципаль районы Янтуган авыл җирлеге муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының кадрлар эшен алып бару буенча аерым функцияләрне Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турында» карарының 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6.1 нче пункт үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә язарга:

«6.1. Әлеге Килешү рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә.»

2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Янтуган авыл җирлеге Советына Буа муниципаль районы Башкарма комитеты белән өстәмә килешү төзергә (1 нче кушымта).

3. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат http://pravo.tatarstan.ru/ рәсми порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru. рәсми рәвештә басылып чыккан көннән башлап законлы көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы
Янтуган авыл җирлеге башлыгы Р.А. Җамалтдинов

ТР Буа муниципаль районы Янтуган
авыл җирлеге Советының 2024 елның
27 маендагы 82-2 номерлы карарына

1 нче кушымта

Янтуган авыл җирлеге муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының кадрлар эшен алып бару буенча аерым функцияләрне Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турында килешүгә өстәмә килешү

Буа шәһәре «____»_________ 2024 ел

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Янтуган авыл җирлеге Советы, Устав нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Янтуган авыл җирлеге башлыгы ____________________йөзендә, алга таба «җирлек Советы» дип аталучы, бер яктан һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты турында 2021 елның 16 сентябрендәге 3-17 номерлы нигезләмә нигезендә эш итүче җитәкче _________________________ йөзендә, бергә «Яклар» дип аталучылар, ул киләчәктә «район Башкарма комитеты» дип атала, икенче яктан, Кадрлар эшен алып бару буенча аерым функцияләрне тапшыру турында килешүгә түбәндәгеләр турында әлеге өстәмә килешүне төзеделәр:

1. Килешүнең 6.1 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә язырга:

«6.1. Әлеге Килешү рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә.

2. Әлеге өстәмә килешү рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

3. Килешүнең барлык башка пунктлары элекке редакциядә гамәлдә кала.

4. Әлеге өстәмә килешү бер үк юридик көчкә ия һәм ике экземплярда төзелгән, һәр як өчен берәр экземпляр.

Яклар имзалары

| | |
|---|---|
| Буа муниципаль районы<br>Янтуган авыл җирлеге башлыгы | ТР Буа муниципаль районы<br>Башкарма комитеты җитәкчесе |
| ________________/ _______________ | ________________/ ________________ |